ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

20.10.2020                                                03

с. Русское Макулово

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең  Клянчино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү  турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»  2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы  Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Клянчино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020нче елның 5нче ноябренә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Клянчино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән   балигъ булмаган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Клянчино авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү

«ӘЙЕ»                    «ЮК»

3. Клянчино авылы, Үзәк урамы, 26нчы йорт адресы буенча 15.00 сәгатьтә Клянчино авыл клубы бинасында халык җыенын үткәрергә.

4. Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы                                        А. И. Матвеева